ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2020 Олы Кайбыч ав. № 228

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының эшчәнлеген туктатып тору турында

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның 2020 елның 9 апрелендәге 17446-МР номерлы, 2020 елның 15 апрелендәге 18609-МР номерлы, яңа коронавирус инфекциясе таралу сәбәпле, эш көне булмаган көннәрдә балалар бакчаларында абонент түләве мәсьәләсе буенча резолюцияләре, Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 02 апрелендәге 239 номерлы Указы нигезендә «Россия Федерациясе территориясендә яңа коронавирус (COVID-19) инфекциясе таралу белән бәйле рәвештә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 239 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 19 мартындагы «Татарстан Республикасы территориясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 208 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 03 апрелендәге 252 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 1 апреленнән санитар-эпидемиологик хәл нормальләшүгә кадәр Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген туктатырга.
2. 2020 елның 1 апреленнән санитар-эпидемиологик хәл нормальләшүгә кадәр Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә эш көне булмаган көннәр өчен хезмәт хакын сакларга.
3. Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 25 мартындагы 206 номерлы Указы гамәлдә булмаган ата-аналар гаризасы буенча (өзлексез эшләүче оешмалар, медицина һәм аптека оешмалары хезмәткәрләре; халыкны беренче кирәкле азык-төлек продуктлары һәм товарлар белән тәэмин итүче оешмалар; гадәттән тыш хәлләр шартларында кичектергесез эшләрне башкаручы оешмалар, халыкның тормышын яки тормыш шартларын куркыныч астына куя торган башка

очракларда; кичектергесез ремонт һәм төяү-бушату эшләрен гамәлгә ашыручы оешмалар) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында дежур төркемнәр оештырырга.

4. Яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә санитар-эпидемиологик хәл нормальләшкәнчегә кадәр үзизоляция гамәлдә булган чорда тәрбияләнүчеләрнең ата-аналары (законлы вәкилләре) өчен, эш көне булмаган көннәрдә дежур төркемнәргә йөрүче тәрбияләнүчеләрнең ата-аналарыннан (законлы вәкилләреннән)кала, балалар бакчаларында абонент түләвен гамәлдән чыгарырга.

5. Шушы чор өчен балалар бакчасына йөрмәгән тәрбияләнүчеләргә карата элек түләнгән абонент түләвен яңадан исәпләргә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы И.И.Хәмидуллинга йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров